Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең
“78 нче “Чыршыкай” катнаш төрдәге балалар бакчасы “ муниципаль бюджет
мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

# УЙНЫЙ - УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ

**0 – 7 яшьлек балалар өчен уенлы шигырьләр**

**Яр Чаллы, 2019**

Кәҗәкәй
Кәҗә керә бакчага
Яшел борчак ашарга...
Таяк тотып чыксалар,
Хәзер тора качарга.
Кәҗә,кәҗә, ми-кә-кә,
Кермә безнең бакчага.
Эләгерсең киртәгә,
Кундырырлар җилкәңә!

***

Кәҗәгә очлы мөгез нәрсәгә?
-Сөзәргә!
-Кәҗәгә каты тояк нәрсәгә?
-Тибәргә!
-Кемне сөзәргә? Кемгә тибәргә?
-Кем ботка ашамый -
Шуны сөзәргә!
Кем сөт эчми -
Шуңа тибәргә!

КҮЛМӘК
Менә күлмәк.
Менә җиңе.
Бусы - күлмәк итәге.
Бусы - баш сыярлык тишек,
Күлмәк авызы бит әле.
Кулым керә шул авызга,
Башым кала төртелеп.
Ярый ла апам булыша,
Тиз генә йөгереп килеп
Куянкай
Әй, куян, куян,
Кечкенә генә,
Бик йомшак кына,
Бик куркак кына.
Ике колагы
Озынкай гына,
Аягы җиңел — Мамыктай гына.

Үзен бик чиста йөртә
Күрәсезме песине,
Юына, чистарына.
Ул кунакка барамы?
Ник юына, арына?

Йомшак тәпие белән
Битен әйбәтләп сөртә.
Ул шулай һәрвакытта
Үзен бик чиста йөртә.
(Җәвад Тәрҗеманов)

Чебиләр
Чи-чи килә чебиләр,
Чи-чи көлә чебиләр,
Чи-чи елый чебиләр,
Чи-чи жырлый чебиләр.

Чи-чи дип, чебиләр,
Туктаусыз сөйләнәләр
Алар бит "Чи-чи" дигән
Яңа җыр өйрәнәләр.

ТӨСЛӘР ӨЙРӘНӘБЕЗ
*Сары* була чебиләр,
Лимон була *сап-сары.*
Сары төскә буялган
Машинам да бар тагын.
Җиләк була *кып-кызыл,*
Мичтә *кызыл* ялкын да,-
ул пешерә. Ни өчен
Бит кызара салкында?
*Яшел* була яфраклар.
Үлән дә яшел була.
Түтәлләрем *ямь-яшел*
Кыярлар белән тула.

*Зәп-зәңгәр* күк йөзендә
*Ак* болыт йөзеп йөри.
*Ап-ак* болыт өстендә
Самолет кына гөжли.

*Кара* туфрак, *кара* җир
Бар төсләрне тудыра.
Кара -матур булмаса да,
Иң матуры - *кап-кара!*

КӘҖӘ БӘТИЕ
Бар минем кәҗә бәтием,

Мин аны үзем көтәм:
Мин иртән кәҗә бәтиен
Бакча башына илтәм.
Югалса,эзлим бакчада-
Кәбестә арасында.

МАТУР СҮЗЛӘР КЕМ БЕЛӘ?

Яшел үләндә бәпкәләр
Йөгерешеп йөрделәр.
Күркә апаларын күреп,
Башларын иеп, елмаеп,
”ИСӘНМЕСЕЗ!”- диделәр.

Бал кортлары Дәү Аюга
Тәпән тутырып бал бирде.
Дәү Аюга бал ошады -
Ашагач, авызын ялап:
“РӘХМӘТЛӘР ЯУСЫН!”- диде.

Маэмаем Кашка Тай белән
Ялкауланып өйдә ятмый,
Киң басуларда йөрде.
Авылга кайтып җиткәчтен:
“ХУШ, ДУСТЫМ, САУ БУЛ!”, - диде.

- ХӘЕРЛЕ КӨН, Сарык дускай!
- ХӘЕРЛЕ КӨН, Сыер дус!
- Килче әйдә, су эчәбез!
- РӘХМӘТ, мин су эчтем инде,
Күләгәле тал астында
Сиңа да бар бер урын!

ПЕСИ ЙӨРИ ШЫМ ГЫНА,
МИЯУЛАМЫЙ ТЫН ГЫНА.
ТУКЫЛДАТМЫЙ ТӘПИЕН,
ЙОКЛАСЫН ДИП БӘБИЕМ.

ҮПКӘЛӘГӘН ДУҢГЫЗ

Әтәчнең - кызыл береты,
Кәҗәнең - җылы жилеты ,
Тавыкның - алсу бантигы,
Ә песинең икешәр пар
Йомшак киез итеге бар.

Сыерның сырлы гармуны!

Дуңгыз әйтә:”Үпкәләдем,
Ашамыйм, ди, боткагызны!
Миңа да ник бирмәдегез,
Ни сәбәптән җәлләдегез -
Мин дә кияр идем бит, ди
Башыма кызыл беретны,
Аркама җылы жилетны,
Аякка киез итекне.
Мин дә тагарга телим, ди
Чәчемә алсу бантикны,
Сыздырып уйнар идем, ди
Тарттырып мин дә гармунны!”

Бу нәни Дуңгыз Баласы
Остазларын тыңламаган.
Аңа алар: “Юын ", -дигәч”,
Ялкауланган, юынмаган.
Шапшак булган шул бичара!
Шуңа күрә аны элек
Керткәннәр бит мунчага:
Чистарын, диеп биргәннәр
Сабын белән мунчала!

***Бөрлегән***
*Гөлшат Зәйнашева*
Бөрлегәнем-җиләгем, дип
Иркәли мине әни.
Мин бит әле бик кечкенә,
Мин бит әле бик нәни.

Зур түгел шул, бик кечкенә,
Бөрлегән мин, бөрлегән.
Бөрлегән генә булсам да,
Бар эшкә дә өлгерәм.

КӨТҮЧЕ
Ямь-яшел киң аланнарда
Көн уздыра көтүче.
Аюлардан, бүреләрдән
Көне буе көтү саклап,
Чыбыркысын чыжылдатып,
Сыбызгысын сызгырткалап,

Сыерларны, сарыкларны
Карап, саклап йөртүче.
Көтүче - терлек ашатып,
Инешләрдә су эчертеп,
Туклаңдырып йөртүче.
Көтүдә йөргән сыерлар -
Боткага май бирүче,
Очлы мөгез кәҗәләре -
Синең кебек нәниләргә
Тәмле сөт эчертүче.

Аяк бармаклары өчен уен.

Бер борчак,(аяк бармакларын берәм-берәм тотып санап чыгу)
Ике борчак,
Өч борчак,
Дүрт борчак,
Биш борчак, ... ун борчак!
Күп борчак.(тиз-тиз генә кирегә таба һәр бармакны тотып чыгу)
Үсеп җитәрләр бер чак,( кулнын баш бармагы белән үкчәдән бармакларга таба йомшак кына сыпырып алу)
Хәтфә үлән өстеннән ( баланын табаны буйлап олы кеше бармакларын “ тәпи” йөртә.)
Йөгереп  китәрләр шул чак.

**Чәбәкәй**

*Хәкимҗан Халиков*

Минем сеңлем Тәнзилә,
Әлегә бик бәләкәй.
Ә шулай да инде ул
Итә белә чәбәкәй.
Менә шулай, менә шулай,
Итә белә чәбәкәй.

Әллә инде шуңарга
Сеңлем бигрәк сөйкемле.
Чәбәк-чәбәк иткәндә
Очып китәр шикелле.
Менә шулай, менә шулай
Очып китәр шикелле.

Көн дә көтәм мин аның
Тып-тып йөреп киткәнен.
Ул чәбәкәй иткәндә

Беркөн биеп киткәнмен.
Менә шулай, менә шулай
Үзем биеп киткәнмен.

***

Мәче утыра киртәдә
Килер, диеп иртәгә,
Бүгенгесенә ни булган?
Җир йөзе акка тулган.
Мәче утыра мут карап,
Эшләре әллә харап?
Алан, йолан караштыра
Җил үтте йонын тарап.
Балалар чана шуалар,
Эт чаба яннарында,
Моржадан тәмле ис килә
Мәче сизә барын да.
Елгаларда боз катмаган,
Яңа кар төшкән җиргә,
Җан иясе хәрәкәттә
Шатлана шуңа җир дә.
Мәче утыра киртәдә
Яңа иртәләр көтеп,
Кыш салкыны тынын өрде
Битләрне алды өтеп.

**САБЫЙЛАРНЫҢ БАЛА ЧАГЫ,**

**КИЛӘЧӘГЕ МАТУР БЕР ҖЫР**

**БУЛСЫН!!!**

**ГОМЕР БҮЛӘК ИТҮЧЕ ДӘ, ТОРМЫШ**

**БУЙЛАП ЙӨРТҮЧЕ ДӘ СЕЗ –**

**ӘТКӘМ – ӘНКӘМ!!!**

**Төзеде: Багаутдинова Альфира Накиповна**